ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

08.11.2024 с. Куралово 02-02/4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставының 24нче статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 26 ноябрендә 11.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 26 ноябрендә 12 сәгать 30 минутка Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнары үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.
1 этап: Рус Борнашы авылы Зур урамы, Цветочная урамы, Кече урамы халкы
2 этап: Рус Борнашы авылы Совет урамы, Дальняя урамы, Заречная урамнары халкы

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:
«Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Бурнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:
- Рус Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Гражданнар җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Рус Борнашы авылы Зур урамы буенча 4нче йорт янында
2 этап: Рус Борнашы авылы Заречная  урамы буенча 1 нче йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово  авыл җирлеге башлыгы Р.Е.Тарасов